**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮҖӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423734, Күҗәкә авылы, Совет ур., 28 йорт.

**СОВЕТ КУЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423734, село Кузякино, ул. Советская, дом 28.

**КАРАР**
**“20”ноябрь 2024 ел.**

**РЕШЕНИЕ**
**№1**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге составына керүче Күҗәкә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Күҗәкә авыл җирлегенең Күҗәкә авылында 2024 елның 20 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.:

«Яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданнан, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, 2025 елда үзара салым түләүне бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә кертүгә ризамы сез? Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Украинадагы махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне, түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтеп:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту( ПГС салу, грейдерлау, кардан чистарту, юл кырыйларын чаптыру)

2.Су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау, торгызу һәм төзекләндерү) тәэмин итә торган су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

3.Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә

ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау(урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау);

4.Торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт территориясендә агачлар кисү,хуҗасыз территорияләр коймаларын ремонтлау;);

5.Россия Федерациясе халыкларының мәдәни объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарҗләре) булмаган һәйкәлләрне төзү,ремонтлау һәм алар янындагы территорияне төзекләндерү (һәйкәлләрне һәм обелискны ремонтлау);

«Риза» "Каршы" «Тыелып калдылар»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 227 граждан, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 119 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Риза» -119 граждан тавыш бирде;

«Каршы»- 0 граждан тавыш бирде.

«Тыелып калдылар»-0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Күҗәкә авыл җирлегенең Күҗәкә авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карарны танырга:

«Яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданнан, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, 2025 елда үзара салым түләүне бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым түләвен кертүгә ризамы сез? Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Украинадагы махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне, түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтергә

3. Әлеге карарны Күҗәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында http://aktanysh.tatar.ru урнаштырырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге Советы Рәисе И.Н.Мусин